ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОТАРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОТАРКА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул.Октябрьская, д.17, с. Отарка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422180

Октябрь ур., 17 нче йорт, Отарка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422180

тел.(факс): (85563) 3-74-77; e-mail: Otar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

---

Постановление — Карар

« 22 » ноября 2019 г. — №54

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Отарка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районының Отарка авыл җирлеге

2019 елның 21 нче ноябрь, 1 нче санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге составына керүче Отарка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башкарма комитеты;

2019 елның 21 нче ноябрь, 2 нче санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге составына керүче“Пятилетка» совхозы поселогы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башкарма комитеты;

к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Отарка авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчасы җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы

Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://mamadysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru). бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Мамадыш муниципаль районы
Отарка авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе /Х.М.Минникаев /

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы
Отарка авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 ел, 22 ноябре, 54 санлы
карарына 1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Отарка авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Отарка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктлары территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар 2020 елның 26 мартка кадәр үзара салым акчаларын җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала

3. Җитди сәбәпләр булганда:

а) вакытлыча эшкә сәләтсезлек,

б) хезмәт командировкасы,

гражданнарга, гариза нигезендә, бер айдан да артмаган вакытка түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга аны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән җиткерелә, шулай ук шәхсән кул куйдыртып яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җибәрелә ала.

Хәбәрнамәдә гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

7. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт

хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

8. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

9. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Отарка авыл җирлеге
Башкарма комитетының 22 ноябрь 2019 ел,
54 санлы карарына 2 нче кушымта

______________________
*(муниципаль берәмлек исеме)*

бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № ________________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
Адрес: ______________________________________________________________
Мамадыш муниципаль районы ___________ авыл җирлегенең __________ авылында гражданнар җыены карары нигезендә 2020 нче елда үзара салым акчаларын куллану һәм кертү мәсьәләсе буенча Сезгә 2020 елда халык җыены чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр ______ сум күләмендә түләүне, түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк: _____________________________________________________

Кабул итүче як банкы БИК _______________________________________
Сч. № ___________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № ___________________________________________
ИНН ____________________________________________
КПП _____________________________________________
КБК _______________ ОКАТО ___________________
Түләүнең билгеләнеше
Гражданнарның үзара салым түләве

Җитәкче __________________ _________________________________________
П. У. (имза) (тулысынча язылыш)

**- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисеп алу сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -**

_________________________________________________________
*(муниципаль берәмлек исеме)*
_________________ сум күләмендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _________________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
_________________________________________________________

Адрес:
________________________________________________________________________
_____
«__» ________________ 20__ г. _______________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, өземтә (корешок)____________________ авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.*